«Хуплыйм»
«Сәләт» проектлары
җитәкчесе
Әдип Әлмир
«12» сентябрь 2023 ел

«Хуплыйм»
ЧР-Чувашиянең Батыр
муниципаль округы башлыгы
Р.В. Селиванов
«12» сентябрь 2023 ел

«Раслыйм»
«Сәләт» ТРЯИФ
Генераль директоры
_____Э.Р. Насибуллина
«12» сентябрь 2023 ел

«Раслыйм»
«Сәләт» яшьләр үзәге
директоры
______А.Т. Габдрахманова
«12» сентябрь 2023 ел

**I регионара «Геннадий Айги һәм Кави Латыйп варислары» ачык әдәби конкурсы**

**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

**1. Конкурсны оештыручылар**

1.1. I регионара «Геннадий Айги һәм Кави Латыйп варислары» ачык әдәби конкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы «Сәләт» иҗтимагый фонды, «Сәләт» яшьләр үзәге, «Сәләт» Клубы, Чувашия Республикасы - Чувашия Батыр муниципаль округы һәм ЯИҮ «Сәләт-Батыр» тарафыннан тормышка ашырыла.

**2. Конкурсның максаты һәм бурычлары**

2.1 Конкурсның максаты – сәләтле яшь авторларның әдәбият өлкәсендәге иҗади потенциалын үстерүдә булышлык күрсәтү.

2.2 Конкурс үз алдына түбәндәге бурычларны куя һәм гамәлгә ашыра:

– әдәбият өлкәсендә сәләтле балаларны һәм яшьләрне барлау, аларга иҗади яктан камилләшүдә, үсүдә ярдәм күрсәтү;

– балаларда һәм яшьләрдә эстетик зәвык һәм әдәби мәдәniяткә мәхәббәт тәрбияләү;

– сәләтле яшь язучыларның игътибарын хәзерге заман әдәбиятына һәм халкының рухи мирасына юнәлдерү;

– төрле милләт халыклары арасында дуслык җепләре булдыру;

– сәләтле яшьләрне Сәләт оешмасы проектларына җәлеп итү.

## 3. Конкурсның номинацияләре

3.1 Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

– татар шигърияте / чуваш шигърияте;

– татар телендә чәчмә әсәр / чуваш телендә чәчмә әсәр;

– татар телендә балалар әдәбияты / чуваш телендә балалар әдәбияты;

– татар драматургиясе / чуваш драматургиясе;

– татар публицистикасы / чуваш публицистикасы.

## 4. Конкурсның казыйлар шурасы

4.1. Конкурска килгән эшләрне бәяләү өчен экспертлар төркеме билгеләнә һәм жюри төзелә. Экспертлар һәм жюри әгъзалары яшь һәм тәҗрибәле иҗатчылар, күренекле җәмәгать эшлеклеләре, мәктәп җитәкчеләре һәм мөгаллимнәрдән сайлана.

4.2. Эшләр экспертларга оештыру комитеты тарафыннан шифрлап тапшырыла. Бәяләүдә гаделлек, объективлык саклау максат итеп куела.

4.3. Әсәрләр экспертлар төркеме һәм жюри әгъзалары тарафыннан алдан әзерләнгән критерийлар нигезендә 10 ар балл исәбеннән бәяләнә. Баллар куелган бәяләү кәгазе, һәр эксперт тарафыннан имзаланып, оештыру комитетына тапшырыла.

Әгәр экспертлар бәяләмәсендә берничә әсәр бер үк баллга ия булса, алар жюри әгъзалары тарафыннан тавыш бирү юлы белән бәяләнә, тавышлар тигез булган очракта жюри рәисе тавышы өстенлек ала.

Жюри карары буенча дәгъвалар кабул ителми.

## 5. Конкурсның катнашучылары

5.1 Конкурста 11 яшьтән алып 21 яшькә кадәр булган сәләтле мәктәп балалары һәм белем бирү оешмалары студентлары катнаша ала.

5.2 Конкурс түбәндәге яшь категорияләре арасында үткәрелә:

– 11-14 яшь;

– 15-17 яшь;

– 18-21 яшь.

Башлангыч сыйныф укучылары, конкурстан тыш катнашып, кызыксындыру бүләгенә ия булырга мөмкин.

## 6. Конкурста катнашучыларның эшләренә карата куелган шартлар

6.1 Конкурста татар яки чуаш телендә иҗат итүче мәктәп укучылары катнаша ала.

Конкурска иҗади эшләр түбәндәге күләмдә кабул ителә:

– шигърият – 2 язмадан күбрәк , 6 язмадан азрак булырга тиеш;

– чәчмә әсәр – 1, яки 2 язма булырга тиеш;

– балалар әдәбияты – 1, яки 2 язма булырга тиеш;

– драматургия – 1, яки 2 язма булырга тиеш;

– публицистика – 2 язмадан күбрәк, 4 язмадан азрак булырга тиеш.

6.2 Конкурста катнашучы теләсә кайсы номинациядә татар яки чуаш телләрендә иҗат иткән әдәби әсәрен тәкъдим итә. Берьюлы 2 номинациядә катнашырга мөмкин.

6.3 Иҗади эшләр өчен авторлар үзләре җавап бирә.

6.4 Конкурска кабул ителгән иҗади эшләр кире кайтарылмый.

6.5 Оештыру комитеты конкурска кабул ителгән эшләрне төрле матбугат чараларында бастырырга хокуклы. Каләмдәше (соавторы) мәктәп яшендә булмаган, республика күләмендә оештырылган башка әдәби бәйгеләрдә катнашкан әсәрләр кабул ителми.

6.6 Конкурста катнашу өчен гаризалар Сәләт оешмасының рәсми сайтында www.selet.biz кабул итеп алына.

6.7 Конкурста катнашучы берничә номинациядә көч сынарга теләсә, аңа тиешле санда гариза тутырырга кирәк.

6.8 Конкурста катнашучы үзе (яшьтәш соавторы булса, *үзләре*) иҗат иткән әсәрне (берничә номинациядә катнашса, *әсәрләрне*) һәм үзе турындагы анкетаны (кушымта) оештыру комитетына selet.varislar@gmail.com адресына 13 нче октябрьгә кадәр юллый. Конкурс эшләре адресы белән электрон почтага кабул итеп алына.

6.8.1 Хатның темасы түбәндәгечә күрсәтелә: Номинация – катнашучының фамилиясе (тулысынча), исеме һәм әтисенең исеме (инициаллары).

*Үрнәк:* Шигърият – Әхмәтшин А.Р., 18 яшь;

6.9 Конкурс эшләре түбәндәге шартларга туры китереп языла:

- шрифт: Times New Roman;
- шрифтның зурлыгы: 14;
- юлара интервал: 1,5;
- әгәр иҗади эш шигырь формасында булса, текст битнең сул ягы буенча тигезләнә; әгәр иҗади эш проза формасында булса, текст бит киңлеге буенча тигезләнә;
- язманың исеме уртада ярымкалын шрифт белән күрсәтелә.

6.10 Конкурс эшенең титул бите түбәндәге пунктлардан гыйбарәт (Кушымта №1 кара):

- катнашучының исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча), телефон номеры;
- номинация;
- катнашучының тулы яше;

- катнашучының уку урыны, сыйныфы (курсы);
- җитәкченең исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча) һәм вазыйфасы, телефон номеры.

6.11 Оештыру эшләренә түләү 700 сум тәшкил итә. Түләү конкурсның финал көнендә регистрация вакытында кабул ителәчәк.

## 7. Конкурсның үткәрелү вакыты һәм урыны

7.1 Бәйге берничә этапта үткәрелә:

1 нче этап**.** 13 нче сентябрь – 13 нче октябрь. Гаризаларны кабул итү,

2 нче этап. 14 нче октябрь - 21 нче октябрь. Экспертлар төркеме тарафыннан барлык әсәрләр арасыннан иң яхшы әсәрләрне (һәр номинациядә һәм яшь категориясендә) сайлап алу.

3 нче этап. 26 нчы - 27 нче октябрь. Бәйгенең финалы. Финал Чувашия Республикасы, Батыр районы, Кызыл-Чишмә авылы, ЯИҮ «Сәләт-Батыр» адресы буенча узачак. Җиңүчеләрне кызыклы программа һәм бүләкләү тантанасы көтәчәк.

## 8. Нәтиҗәләр ясау

8.1. Һәр номинациядә яшь категорияләрендә җиңүчеләр һәм номинантлар билгеләнә. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырыла. Шулай ук конкурста катнашкан һәркемгә катнашучы сертификаты һәм катнашучыны әзерләгән җитәкчегә рәхмәт хаты каралган.

8.2. Конкурс нәтиҗәләре нигезендә «Гран-при» иясе билгеләнәчәк.

8.3. Конкурсның оештыру комитеты белән килешеп, Казыйлар шурасы махсус бүләкләр бирү хокукына ия.

8.4. Гомуми карар белән Казыйлар шурасы Конкурста Гран-при иясен билгеләмәскә хокуклы.

## 9. Конкурсны оештыру комитетының контактлары

Конкурсны оештыру комитеты Сәләт Йортында (Казан, Островский ур., 23-нче йорт) урнашкан. Белешмәләр өчен телефон: +7(843) 292-16-00.

Конкурсның җитәкчесе: Гатина Гөлназ Шәүкәт кызы, +79003268636.

E-mail: selet.varislar@gmail.com

Сәләт оешмасының рәсми сайты: www.selet.biz.

«ВКонтакте» социаль челтәрендә Сәләт оешмасының рәсми төркеме: https://vk.com/selet.official.

Кушымта 1.

1. Катнашучының исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча), телефон номеры;
2. Номинация;
3. Катнашучының тулы яше;
4. Катнашучының уку урыны, сыйныфы (курсы);
5. Житәкченең исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча), вазыйфасы һәм телефон номеры.